**Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы**

**Бәзәкә авыл җирлеге Советы**

КАРАР

2021 нчеелның 9 нчы ноябрендәге 27нче номерлы

“Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегендә бюджет процессы турында " гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы

Караритте:

1. 2020 нче елның 3 нче февралендәге 2 нче номерлыТатарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегендә бюджет процессы турында”гы Нигезләмәгә" нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында:

1.1. Нигезләмәнең 15 нче статьясындагы 12 нче пунктының 2 нче пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш , тикшереп торуны гамәлгә ашыра;;

1.2. Нигезләмәнең 35 нче статьясындагы 27 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "кредит (займ) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турындагы шартнамәдә кредитор (заемчы) йөкләмәләрен үз ягыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларының максатчан кулланылышын тикшереп тору шарты белән бирелә.";

1.3. Нигезләмәнең 13 нче статьясындагы 3 нче пунктының 5 нче пунктчасына "Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш"сүзләрен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 13 нче статьясындагы 2 нче пунктының 4 нче пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4)Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен үзләренә беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр бирә;";

1.5. Нигезләмәнең 41 нче статьясындагы 1 нче өлешен  яңа өченче абзац итеп түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

1)Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документларда;

2) өченче – дүртенче абзацларны дүртенче - бишенче абзацлар дип санарга;

2. Әлеге карарны Бәзәкә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштырып таныштырырга, Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге бүлегерәсми сайтындаwww.mendeleevsk.tatar.ru шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Бәзәкә авыл җирлеге рәисе
И.И.Кашафутдинов